Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге составына керүче Үчкә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

# КАРАР

2025нче елның 28 ноябре № 1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2025 елның 28 ноябрендә уздырылган «Түбән Кама муниципаль районының Каенлы авыл җирлеге Үчкә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның хатыннары/ирләреннән тыш, 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү белән килешәсезме:

– су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау.

«ӘЙЕ» «ЮК».

мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 135 җыенда катнашучы граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан җыенда катнашучы гражданнар саны 97 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде: «Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 86 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 11 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге составына керүче Үчкә торак пунктында гражданнар җыенын булган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Түбән Кама муниципаль районының Каенлы авыл җирлеге Үчкә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек

Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның хатыннары/ирләреннән тыш, 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү белән килешәсезме:

– су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

«ӘЙЕ» «ЮК»

мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына, Каенлы авыл җирлеге сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Каенлы авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Гарипов

«Совет «Каенлинского сельского поселения Нижнекамского муниципального района Республики Татарстан»